## 30.03.2026 ЭЛЕКТРОН ФОРМАДА ГАВАМИ ТӘКЪДИМ АША САТУ **ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТИ ХӘБӘР**

**1** **Сату формасы:** Гавами тәкъдим ярдәмендә сату (алга таба – сату) мондый сатуны үткәрүнең бер процедурасы дәвамында муниципаль мөлкәт сатып алу турында тәкъдимнәр бирүнең ачык рәвешеннән файдаланып гамәлгә ашырыла. Сатулар электрон формада үткәрелә.

Сату Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 447, 448 статьялары, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2002 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сатуны оештыру һәм уздыру турында» 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары кагыйдәләре буенча һәм нигезендә, «Муниципаль милекне гавами тәкъдим аша сату турында» 2025 елның 14 февралендәге 7 номерлы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә үткәрелә.

Мөлкәт Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Башкарма комитетының (алга таба – Оешма) муниципаль милке булып тора. Оешма Россия Федерациясе Салым кодексының 145 статьясындагы 1 пункты нигезендә өстәлгән бәягә салым (алга таба – НДС) исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүче вазыйфаларын башкарудан азат ителгән, шуңа бәйле рәвештә мөлкәткә НДС салынмый.

**2** **Электрон мәйданчыкта сатуларны оештыру буенча Сатучы функцияләре бирелгән оешма:** Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге башкарма комитеты (Нигезләмә нигезендә гамәлдә)

Урнашу урыны: 422117, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Березняк ав., Ленин ур., 17 й.

тел: (84364)35-2-02 – Шәрипов Рөстәм Фирдаил улы

Электрон почта адресы: Berez.Kuk@tatar.ru

**3** **Сатуны оештыручы (электрон мәйданчык операторы):** «Татарстан Республикасы Дәүләт заказы агентлыгы» АҖ

Урнашу урыны: 420021, Татарстан Республикасы, Казан ш., Мәскәү ур., 55;

Тел. (843) 292-95-17 – Голованов Михаил Юрьевич. Техник ярдәм күрсәтү хезмәте – (843) 212-24-25

**4** **Электрон формада сату уздырылачак электрон мәйданчыкның адресы:** Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 04 декабрендәге 2448-р номерлы боерыгы белән расланган – «Татарстан Республикасының Дәүләт заказы агентлыгы» АҖ электрон мәйданчыгы – **sale.zakazrf.ru**.

**5** **Дәүләт мөлкәте исеме (мөлкәт характеристикалары):**

| **Лот номеры** | **Мөлкәт исеме (характеристикалары)** | **Беренчел тәкъдимнең бәясе (НДС белән күрсәтелгән), сум.** | **Тәкъдимнең минималь бәясе («иң түбән бәя»), сум** | **Бәяне күтәрү адымы («аукцион адымы»), сум.** | **Бәяне төшерү адымы, сум.** | **Задаток, сум.** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җиңел автомобиль LADA NIVA 212300-55, 2020 елда чыгарылган, 119000 км йөргән, кузов төсе соры, VIN X9L212300L0715976 | 660000 | 330000 | 16500 | 33000 | 66000 |

Карауны оештыру яисә өстәмә мәгълүмат алу мәсьәләләре буенча эш көннәрендә 09:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр Оешма җитәкчесе Шәрипов Рөстәм Фирдаил улына мөрәҗәгать итәргә, тел: 89274001142. Автомобильнең хәзерге вакытта тору урыны адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Березняк авылы, Ленин урамы, 17 й.

**Объектны карап чыгу һәм аның техник документларын өйрәнүгә үз хокукын гамәлгә ашырмаган сатуларда җиңүче объектның юридик, физик һәм финанс хәле уңаеннан сатучыга дәгъва белдерү хокукыннан мәхрүм ителә.**

**Хокукны чикләү һәм обременение:** юк.

| | |
|---|---|
| | **Автомобильнең техник торышы турында мәгълүмат:** техник яктан уртача хәлдә. Куланырга яраклы. |
| 6 | **Милекне сатуга кадәр бер ел эчендә игълан ителгән милекне сату буенча алдагы барлык торглар турында һәм мондый милекне сату буенча сәүдәләр йомгаклары турында белешмәләр:**<br>20.02.2026 га билгеләнгән аукцион гаризалар булмау сәбәпле узмады. |
| 7 | **Задаток кертү турындагы таләп.** Задаок суммасы дәгъвачының электрон мәйданчыкта теркәлгәндә ачылган виртуаль счетына күчерелә (кертелә). Сатуларда катнашу өчен задатокны күчерү буенча күрсәтмәләр sale.zakazrf.ru мәйданчыгында «Документлар», алга таба «Инструкцияләр», алга таба «Катнашуга гаризаны тәэмин итү сыйфатында задатокны күчерү өчен счет реквизитлары» бүлегендә урнаштырылган. Әлеге хәбәр РФ ГК ның 437 статьясы нигезендә задаток турында килешү төзү өчен ачык оферта булып тора, ә дәгъвачы тарафыннан гариза бирү һәм задаток күчерү мондый офертаның акцепты булып тора, шуннан соң задаток турында килешү язма рәвештә төзелгән дип санала. |
| 8 | **Сатуда катнашуга дәгъва кылучыларны Электрон мәйданчыкта теркәү датасы, вакыты һәм тәртибе:**<br>**sale.zakazrf.ru** мәйданчыгында сатуларда катнашу мөмкинлеген алу өчен, кулланучы электрон мәйданчыкта аккредитация процедурасын узарга тиеш.<br>Аккредитация инструкциясе «Документлар» бүлегендә урнаштырылган, кара «Оешманы теркәү буенча инструкция».<br>Аукционда катнашу буенча инструкция «Документлар» бүлегендә урнаштырылган, кара «Катнашучыга инструкция». Электрон мәйданчык тәүлек буе эшли. |
| 9 | **Гаризалар бирү тәртибе, урыны, башлану һәм тәмамлану даталары:**<br>Аукционда катнашуга гаризалар бирү срогының башлану датасы аукцион уздыру турында мәгълүмати хәбәрне торглар уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында [www.torgi.gov.ru,](http://www.torgi.gov.ru) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы сайтында [www.kukmor.tatarstan.ruInsert](http://www.kukmor.tatarstan.ru), электрон мәйданчыкта **sale.zakazrf.ru** урнаштырган көннең иртәгесе дип санала.<br>**Гаризалар кабул итә башлау датасы: *27.02.2026, 09.00 сәг.***<br>**Гаризалар кабул итүнең тәмамлану датасы: *25.03.2026, 17.00 сәг.***<br>Электрон формада сатуда катнашу өчен дәгъвачылар электрон мәйданчыкта – **sale.zakazrf.ru** – теркәлергә тиеш.<br>**Гариза бирү тәртибе:**<br>Гариза электрон мәйданчыкның чикләнмәгән затлар даирәсе өчен ачык булган өлешендә (алга таба – электрон мәйданчыкның ачык өлеше) урнаштырылган электрон формасын тутырып, документларның электрон рәвешләрен кушып бирелә.<br>Бер зат бары тик бер генә гариза бирергә хокуклы.<br>Дәгъвачылардан гаризалар кабул иткәндә, оештыручы гаризаларны һәм аларга беркетелгән документларны гаризалар кабул итү журналында теркәүне тәэмин итә. Һәр гаризага кабул итү датасы һәм вакыты күрсәтелгән номер бирелә.<br>Гариза кергән вакыттан алып бер сәгать эчендә оештыручы, теркәлгән гаризаның һәм аңа беркетелгән документларның электрон күчермәләрен кушып, хәбәрнамә җибәреп, дәгъвачыга гариза килүе турында хәбәр итә.<br>Билгеләнгән срокны бозып тапшырылган аңа беркетелә торган документлар белән гаризалар электрон мәйданчыкта теркәлми.<br>**Гаризаны кире алу тәртибе:**<br>Дәгъвачы гаризаларны кабул итү тәмамлану вакыты көненнән дә соңга калмыйча, электрон мәйданчыкка гаризасын кире алу турында хәбәрнамә җибәрү юлы белән гаризасын кире алырга хокуклы.<br>Гаризаны кире алу турында хәбәрнамә гариза белән бергә бер сәгать эчендә сатучының «Шәхси кабинетына» керә, бу хакта дәгъвачыга тиешле хәбәрнамә җибәрелә.<br>Дәгъвачыдан кергән задаток гаризаны кире алу турында хәбәрнамә кергән көннән алып 5 календарь көн эчендә кире кайтарылырга тиеш. Гаризаны дәгъвачы гаризалар кабул итү тәмамланган көннән соңрак кире алган очракта, задаток милекне сатуда катнашуга кертелмәгән дәгъвачылар өчен билгеләнгән тәртиптә кире кайтарыла<br>. |

| | |
|---|---|
| 10 | **Сатуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге һәм аларны рәсмиләштерүгә таләпләр:**<br>Сатуларда мөлкәтне сатуда катнашу өчен дәгъвачылар гаризаның электрон формасын исемлек нигезендә электрон документларне теркәп тутыралар:<br>**физик затлар** шәхесне таныклаучы документны яисә аның барлык битләренең күчермәләрен бирә, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын белдерә;<br>**юридик затлар** гамәлгә кую документларының таныкланган күчермәләрен, директорны билгеләп кую турында югары идарә органы беркетмәсен, юридик затның устав капиталында дәүләт өлеше турында белешмәләрне, мөлкәт сатып алу турында югары идарә органының язма формадагы карарын (әгәр бу дәгъвачының гамәлгә кую документлары нигезендә кирәк булса), вәкилгә ышанычнамәсен тапшыралар. Шәхси белешмәләр булган документлар тапшырылган очракта, шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык бирү таләп ителә.<br>Гариза һәм аңа беркетелгән документлар электрон рәвештә тапшырыла (сканерланырга тиеш).<br>**Сатуда физик һәм юридик затларның аерым категорияләренең катнашуына чикләүләр** «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясында билгеләнгән. |
| 11 | **Сатып алучыларны мәгълүмат белән таныштыру тәртибе:**<br>Сатуда катнашу өчен гаризаны рәсмиләштерү мәсьәләләре буенча эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 08:00 дән 17:00 гә кадәр (төшке аш 12:00 дән 13:00 гә кадәр) 89274001142 телефоны аша Шәрипов Рөстәм Фирдәил улына һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә: Berez.Kuk@tatar.ru.<br>Аккредитацияләү һәм **sale.zakazrf.ru** мәйданчыгында сатуларда катнашу турында өстәмә мәгълүмат алу мәсьәләләре буенча дүшәмбедән җомгага кадәр Мәскәү вакыты белән 8:30 дан 16:00 гә кадәр Техник ярдәм хезмәтенә –тел. (843) 212-24-25, sale@mail.zakazrf.ru – мөрәҗәгать итәргә. |
| 12 | **Урнаштырылган мәгълүматка карата аңлатмалар алу:** Электрон мәйданчыкта теркәлүгә карамастан, теләсә кайсы зат сатуны оештыручының электрон адресына урнаштырылган мәгълүматны аңлату турында сорату җибәрергә хокуклы, әмма гаризалар бирү тәмамланырга кимендә 5 эш көне кала. Сорату кергән көннән алып 2 эш көне эчендә оештыручы, соратуның предметын күрсәтеп, әмма сорату биргән затны күрсәтмичә, һәркемгә ачык аңлатма урнаштыра. |
| 13 | **Катнашучыларны билгеләү һәм сатуда катнашуга гаризаларны карау көне**: ***27.03.2026, 10.00 сәг.***<br>Дәгъвачыларны сатуда катнашучылар дип тану турындагы беркетмәгә имза салынган көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза биргән барлык дәгъвачыларга аларны сатуда катнашучылар дип тану турында яисә, баш тарту нигезләрен күрсәтеп, сатуда катнашучылар дип танудан баш тарту турында хәбәрнамә җибәрелә.<br>Сатуда катнашуга кертелмәгән дәгъвачылар турында мәгълүмат электрон мәйданчыкның ачык өлешендә, торглар уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында **www.torgi.gov.ru,** Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы сайтында **www.kukmor.tatarstan.ru**, электрон мәйданчыкта – **sale.zakazrf.ru** урнаштырыла. |
| 14 | **Сатуны электрон формада уздыру датасы һәм вакыты: *30.03.2026***<br>**Башлана: 09.00 сәг.** (сату процедурасын үткәрү вакыты электрон мәйданчык эшли торган җирле вакытка туры килә).<br>**Сатуны электрон рәвештә уздыру кагыйдәләре:**<br>Мөлкәтне сату процедурасы мөлкәтне гавами тәкъдим ярдәмендә мөлкәтне беренчел тәкъдим бәясен эзлекле рәвештә «бәяне төшерү адымы»на тигез, әмма иң түбән бәядән ким булмаган зурлыкка төшерү юлы белән сату турындагы мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән көнне һәм вакытта үткәрелә.<br>«Бәяне төшерү адымы» гавами тәкъдим ярдәмендә милекне сату процедурасы дәвамында үзгәрми.<br>Катнашучыларның башлангыч тәкъдимнең бәясе турындагы тәкъдимнәрен кабул итү вакыты гавами тәкъдим ярдәмендә милекне сату процедурасын үткәрү башланганнан соң 1 сәгать һәм һәр «бәяне төшерү адымы»нда милекнең бәясе турындагы тәкъдимнәрне тәкъдим итүгә 10 минут тәшкил итә.<br>Башка катнашучыларның тәкъдимнәре булмаганда, беренчел тәкъдимнең бәясен яки тиешле «бәяне төшерү адымы»нда барлыкка килгән тәкъдимнең бәясен раслаган катнашучы җиңүче дип танылa.<br>Әгәр катнашучыларның теләсә кайсы беренчел тәкъдимнең бәясен яки берәр «бәяне төшерү адымы»нда барлыкка килгән тәкъдимнең бәясен расласа, барлык катнашучылар белән сату түбәндә күрсәтелгечә үткәрелә. Сатуда мөлкәтнең башлангыч бәясе беренчел тәкъдим бәясе яисә |

| | |
|---|---|
| | әлеге «бәяне төшерү адымы»нда барлыкка килгән тәкъдимнең бәясен була. Катнашучыларның милек бәясе турындагы тәкъдимнәрен кабул итү вакыты 10 минут тәшкил итә. «Аукцион адымы» сатучы тарафыннан «бәяне төшерү адымы»ның 50 процентыннан артмаган күләмдә беркетелгән суммада билгеләнә һәм милекне гавами тәкъдим ярдәмендә сату процедурасы дәвамында үзгәрми. Әгәр катнашучылар мөлкәтнең башлангыч бәясеннән артыграк бәя турында тәкъдим белдермәсәләр, мөлкәтнең башлангыч бәясен беренче булып раслаган катнашучы җиңүче дип таныла.<br><u>Сатуларны үткәрү тәртибе (белешмә өчен):</u><br>Сату процедурасын үткәргәндә, оештыручы катнашучыларга электрон мәйданчыкның ябык өлешенә керү мөмкинлеген һәм аларның мөлкәт бәясе турында тәкъдимнәр кертү мөмкинлеген булдыра.<br>Сату процедурасы башланганнан алып 1 (бер) сәгать эчендә катнашучыларга мөлкәтне башлангыч бәядән сатып алу турында хәбәр итәргә тәкъдим ителә. Күрсәтелгән вакыт эчендә:<br>а) мөлкәтнең башлангыч бәясе турында тәкъдим кергән очракта, мөлкәт бәясенең «аукцион адымы»на арттырылган бәясе турында алдагы тәкъдимнәрне кертү өчен вакыт һәр алдагы тәкъдимне керткәннән соң 10 минутка озайтыла. Әгәр мөлкәтнең бәясе турындагы соңгы тәкъдимне керткәннән соң 10 минут эчендә киләсе тәкъдим кермәсә, сату электрон мәйданчыкның программа-аппарат чаралары ярдәмендә тәмамлана;<br>б) мөлкәтнең башлангыч бәясе турында бер генә тәкъдим дә кермәгән очракта, аукцион электрон мәйданчыкның программа-аппарат чаралары ярдәмендә тәмамлана. Бу очракта мөлкәтнең бәясе турындагы тәкъдимнәрне тапшыру тәмамлану вакыты булып сатуның тәмамлану вакыты тора. |
| **15** | **Җиңүчене билгеләү тәртибе:**<br>Гавами тәкъдим аша сатуда башка катнашучыларның тәкъдимнәре булмаганда, муниципаль мөлкәтне сатып алу хокукы беренчел тәкъдимнең бәясен яки тиешле «бәяне төшерү адымы»нда барлыкка килгән тәкъдимнең бәясен раслаган гавами тәкъдим аша сатуда катнашучыга бирелә. |
| **16** | **Сатуга йомгак ясау урыны һәм вакыты:**<br>Сатулар тәмамланганнан соң, аны үткәрү урыны буенча.<br>Сату процедурасы сатучы сату йомгаклары турындагы беркетмәгә кул куйган вакыттан соң төгәлләнгән дип санала. Сату йомгаклары турындагы беркетмә җиңүченең мөлкәтне сату-алу шартнамәсен төзү хокукын раслый.<br>Сату йомгаклары турындагы беркетмәгә кул куелганнан соң бер сәгать эчендә җиңүчегә аны җиңүче дип тану турында, әлеге беркетмәне теркәп, хәбәрнамә җибәрелә. |
| **17** | **Сатуда катнашучыларга задатокларны кире кайтару:** Сатуда катнашу өчен задаток күчергән затларга акчалар түбәндәге тәртиптә кире кайтарыла:<br>а) катнашучыларга, җиңүчедән тыш – сатуга йомгак ясаган көннән алып 5 календарь көн эчендә;<br>б) мөлкәтне сатуда катнашуга кертелмәгән дәгъвачыларга – дәгъвачыларны сатуда катнашучылар дип тану турындагы беркетмәгә кул куелган көннән алып 5 календарь көн эчендә. |
| **18** | **Сату-алу шартнамәсен төзү срогы һәм шартлары**:<br>Сату-алу шартнамәсе электрон документ формасында төзелә.<br>Аукционга йомгак ясалганнан соң 5 эш көне эчендә **җиңүче яисә аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат белән** мөлкәтне сату-алу шартнамәсе төзелә. **Җиңүче яисә аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат тарафыннан** кертелгән задаток сату-алу шартнамәсе нигезендә сатып алынган мөлкәткә түләү исәбенә кертелә.<br>**<u>Җиңүче яисә аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган зат</u> мөлкәтне сату-алу шартнамәсен билгеләнгән срокта төзүдән читләшкән яисә баш тарткан очракта, аукцион нәтиҗәләре сатучы тарафыннан юкка чыгарыла, <u>җиңүче яисә аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган зат</u> күрсәтелгән шартнамәне төзү хокукын югалта, <u>аңа задаток кире кайтарылмый</u>!**<br>**Билгеләнгән срокларда мөлкәт өчен түләүдән баш тарткан яисә читләшкән очракта, сатып алучының җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә мөлкәтне сату-алу шартнамәсендә карала, аңа задаток кире кайтарылмый.** |
| **19** | **Сатып алучыларны сату-алу шартнамәсе шарты белән таныштыру тәртибе:**<br>Сату-алу шартнамәсе проекты торглар уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында **<u>www.torgi.gov.ru</u>**, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы сайтында **<u>www.kukmor.tatarstan.ru</u>** «Авыл җирлекләре» бүлегендә, электрон мәйданчыкта – sale.zakazrf.ru урнаштырылган. |

| | |
|---|---|
| **20** | **Өстәмә белешмәләр:**<br>1. Дәгъвачылар, Сатуда катнашучылар, Сатучы һәм Сатуны оештыручы арасында документлар әйләнеше электрон документлар яисә Дәгъвачы исеменнән эш итәргә хокуклы затның электрон имзасы белән таныкланган документларның электрон образлары рәвешендә, гади язма формада төзелә торган мөлкәтне сату-алу шартнамәсеннән тыш, электрон мәйданчык аша гамәлгә ашырыла.<br>2. Электрон мәйданчыкта электрон документлар төзү, алу һәм җибәрү вакыты электрон мәйданчык эшләгән җирле вакытка туры килә. |
| **22** | Сатучы 2026 елның 25 мартына кадәр аукцион үткәрүдән баш тартырга хокуклы. |

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык
Аукцион комиссиясе рәисенә
кемнән ............................

---------------------------

---------------------------
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

теркәлгән адресы: ____________________________________________

---------------------------------

----------------------------------
(теркәлү адресы
почта индексы белән күрсәтелә)
паспорт сериясе ______ № ___________

бирелгән: ____________________________

----------------------------------
(бирелү датасы һәм
документны биргән орган атамасы)
тел. ______________________________
ИНН______________________

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә РИЗАЛЫК**

Мин, ________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә,
- законнарның һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешен тәэмин итү,
- «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелә торган аукционда катнашу максатыннан

**РИЗАЛЫК БИРӘМ**

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 15 йорт адресында урнашкан Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына минем шәхси белешмәләремне автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча эшкәртү, атап әйткәндә, "Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга.

Эшкәртүгә мин ризалык бирә торган шәхси мәгълүматларым исемлеге:
- фамилиясе, исем, әти исеме;
- җенес, яшь;
- туу датасы һәм урыны;
- паспорт мәгълүматлары;
- яшәү урыны буенча теркәлү адресы һәм фактта яшәү адресы;
- телефон номеры (өйнеке, кәрәзле);
- аукционда катнашуга гаризада мин күрсәткән мәгълүматлар.

Әлеге ризалык аңа кул куйган көннән алып язма рәвештә кире алу көненә кадәр гамәлдә була.

------- ----------
(имза) (имзаның расшифровкасы)

----------
(дата)